ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 Казан ш. № 505-133/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 №119-12/кс-2020 карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү турында һәм «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 №119-12/кс-2020 карары нигезендә билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, оешма тарафыннан эксплуатацияләнә торган объектларны конкретлаштыру һәм 2023 елга җайга салынулы оешманың агып җыела торган суны транспортлауга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны транспортлауга 2021-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 28.10.2020 № 119-12/кс-2020 карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт

комитетының 19.11.2021 № 317-71/кс-2021 карары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТатСтройКа» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агып җыела торган суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.10.2020 № 119-12/кс-2020 карары нигезендә билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында» 19.11.2021 № 317-71/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
28.10.2020 № 119-12/кс-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.11.2022 № 505-133/кс-2022
карары редакциясендә)

Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «ТатСтройКа» ҖЧҖ өчен
2021-2023 елларга агып җыела торган суларны транспортлауга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр |
| | Зеленодольск муниципаль районы, Осиново авылы, Майская, Шуравин урамнары буенча канализация челтәрләре | | | | | |
| 1 | «ТатСтройКа» ҖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 2,84 | 2,92 | 2,92 | 3,04 | 3,16 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге